# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

22.02.2017 ел Иске Дөреш авылы № 19/2

**Иске Дөреш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Иске Дөреш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Россия Федерациясе Граждан кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Уставына, «15» февраль 2017 ел № 02-08-02 прокурор протестына таянып,

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2012 елның 14 ноябрендәге 21 номерлы «Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертергә:

1) Кагыйдәләрнең 3.7.1, 3.7.4, 4.3.3, 4.3.4, 4.4.3, 8.1.5, 8.2.2, 9.13, 11.4 пунктларын гамәлдән чыгарырга;

3.7.3 пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга;

2) Кагыйдәләрнең 3.14 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

3.14. Көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү куркынычның 1 - IV класслы калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру эшчәнлеген башкаруга лицензиясе булган оешмалар тарафыннан калдыкларны урнаштыру объектларында гамәлгә ашырыла.

2) 4.4.1 пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга;

3) 4.4.2 пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга;

4) 7.2.1 пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга;

5) 7.2.1 пунктының 2, 3, 4, 5, 6, 7 а төшереп калдырырга;

6) Кагыйдәләрнең 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә.:

9. Гомуми файдаланудагы территорияләрдә һәм муниципаль милектәге яки милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрендә үсүче яшел үсентеләрне яшелләндерүгә һәм карап тотуга карата таләпләр.

6) кагыйдәләрнең 13 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә.:

13.Җирлекнең муниципаль милкендә булган сулыкларны, зиратларны карап тоту.

7) «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2016 елның 2 ноябрендәге 16/1 номерлы муниципаль берәмлек Советы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Иске Дөреш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Дөреш авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе И.Х.Бакиров